**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 04 май | № 281

г. Казань

Бөгелмә муниципаль районының табигый объектларын төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәлләр дип игълан итү турында

«Аерым сакла244ныла торган табигый территорияләр турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, биологик төрлелекне саклау, хуҗалык һәм бүтән эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохитка тискәре йогынтысын булдырмау, Бөгелмә муниципаль районында уникаль ландшафт комплексларын саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 1309,0 гектар гомуми мәйданлы «Рычкова урман-даласы», «Липовка табигый ызаны», «Коробков сөзәклеге» табигый объектларын төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәлләр дип, ә алар урнашкан территорияләрне төбәк әһәмиятендәге аерым саклана торган табигый территорияләр игълан итү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

500,8 гектар мәйданлы «Рычкова урман-даласы» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле чикләре;

«Рычкова урман-даласы» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле территориясен аерым саклау режимы;

748,1 гектар мәйданлы «Липовка табигый ызаны» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле чикләре;

«Липовка табигый ызаны» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле территориясен аерым саклау режимы;

60,10 гектар мәйданлы «Коробков сөзәклеге» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле чикләре;

«Коробков сөзәклеге» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәле территориясен аерым саклау режимы.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына «Рычкова урман-даласы», «Липовка табигый ызаны», «Коробков сөзәклеге» төбәк әһәмиятендәге

табигый һәйкәлләре чикләре турында мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә «Дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына тапшыруны һәм Татарстан Республикасында аерым саклана торган табигый территорияләрнең дәүләт реестрына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков